


8 сентябрьдә Россиядә Финансист коне билгеләп vтелде. Kvп нәрсә аларнын ьонәри осталыгына, тогәллегенә ьәм ныклыгына бәйле. Белемлелек ьәм игътибарлылык, жаваплылык ьәм фаразлый белv, интеллект ьәм коммуникабельлек – профессиональ финансистнын шәхси сыйфатларынын тулы булмаган исемлеге. Kадошкино муниципаль районы хаки-миятендә алты финансист эшли: Наталья Викторовна Камышова, Светлана Әминовна Байчурина, Любовь Владимировна Лапшина, Альбина Әнвәр кызы Поташова, Наталья Юрьевна Захаркина. Ә бvлек белән Надия Руслан кызы Уторова житәкчелек итә. Алар барысы да, ьичшиксез, бик белемле ьәм жаваплы, vз эшләренен осталары.

Светлана Әмин кызы Байчурина Кадошкино муниципаль районы администрациясенен финанс бvле-гендә 2005 елдан алып эшли. Анын турында барлык коллегалар да бик ях-шы фикердә. Ул ьәрбер эшкә жаваплы могаләмәдә, аралашучан, беркайчан да ярдәмнән баш тартмаячак, диләр анын турында. Тик анын бер минусы бар – vзен мактый алмый. Моннан тыш, Светлана Әминовна vз эшен яхшы белә, ул әле менә дигән хужабикә дә. Анын vз йорты, бакчасы, ишегалдында чебиләр, vрдәкләр, сарыклар бар. Латышовка авылында яши бит ул, әмма районда эшли. Бу юлны (7 км) vтәр очен дә вакыт табарга кирәк бит. Әмма 15 ел эчендә ул ияләште инде.

Светлана тумышы белән Латыш авылыннан, әмма ана биш яшь булганда, әти-әнисе Кадошкино бистәсенә кvчеп яши башлый. Ә язмыш vз юлын сала: 2001 елда киявгә чыккач, туган авылына әйләнеп кайта ул. Ире Илшат белән алар Фаиль белән Эльвинаны тәрбиялиләр. Cvз унаенда, улы быел Н.П. Огарев исемендәге МДУнын электроника ьәм светотехника факультетынын беренче курсына укырга керде, ә кызы алтынчы сыйныфка китте.

Светлана Әминовна Кадошкино урта мәктәбенен 10нчы сыйныфын тәмамлаганнан сон, Н.П. Огарев исе-мендәге МГУнын икътисад факультетына укырга керә. Дорес, читтән торып укыган. Администрациягә әйдәп баручы белгеч булып эшләргә килә, аннары аны баш итеп билгелиләр, хәзер финанс идарәсе консультанты вазыйфасын vти. Әнгәмәдәшебез vзе әйткәнчә, беренче вакыт бик авыр булды, әмма хезмәттәшләре кыенлыкларны жинәргә булыштылар. Коллектив бик тату.

- Мина ьонәрем ошый, - дип билгеләп vтә Светлана Әминовна. - Саннар белән эшләргә, санарга, жыярга яратам... ә менә инша яза алмыйм. Гәрчә укырга бик яратсам да. Дорес, укырга бик ук вакыт калмый. Финансист эше бик катлаулы бит. Законнар vзгәрә, ьәм ьәрвакыт хәбәрдар булу очен, бу vзгәрешләрне кvзәтеп торырга кирәк. Финанс олкәсе хезмәткәре очен белем беренче урында. Ә безнен коллективта бар да яхшы! Тату

коллективта эшләv vзе бәхет бит.

Наилә НАСЫРОВА